**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында 2023 елны Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан итү турында**

Рухи хәзинәләрне саклау һәм баету, борынгы милли гореф-гадәтләрне яңадан торгызу максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында 2023 елны Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

өч ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын уздыруның төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында чаралар уздыру эшен оештырырга.

4. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 20 октябрь
№ ПУ-750